ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

# «Татарстан Республикасы территориясендә салым салуның патент системасын кертү турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2025 елның 24 декабрендә
кабул ителде

## 1 статья

«Татарстан Республикасы территориясендә салым салуның патент системасын кертү турында» 2012 елның 29 сентябрендәге 65-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (2020 елның 25 декабрендәге 90-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә) (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2012, № 9; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2021, № 1 (I өлеш), № 36 (I өлеш); 2022, № 77 (I өлеш); 2023, № 73 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 2 статьяның 1 өлешендәге 44 пунктын үз көчен югалткан дип танырга;

2) 3 статьяның 2 өлешендәге беренче абзацында «34 – 44» саннарын «34 – 43» саннарына алмаштырырга;

3) 4 статьяда:
а) 1 өлешнең 1 пунктында «34 – 44» саннарын «34 – 43» саннарына алмаштырырга;
б) 2 өлешнең беренче абзацында «34 – 44» саннарын «34 – 43» саннарына алмаштырырга.

## 2 статья

Әлеге Закон 2026 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Рәисе — Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2025 ел, 26 декабрь
№ 95-ТРЗ